**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

__08.05.2024_________ ___517-п______

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 9 августындагы 679-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затлар гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 9 августындагы 679-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2023 елның 23 октябрендәге 1238-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затлар гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, 1 бүлекнең 1.2 пунктында 2 пунктчаны түбәндәгечә бәян итәргә:

«2) эксплуатацияләүче оешма милек хокукында яки башка законлы нигездә гидротехник корылмага ия булган юридик зат яки шәхси эшкуар.».

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А. Тугушевка йөкләргә.

4. Әлеге боерык 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков